

# ГӘРӘБӘ

## *Әдәби берләшмә газетасы*

№3-4

Әйсин, телем, айлы төнем,якты көнем.

Әремнәрдән әче, балдан татлы телем.

Сине саклап калыр өчен, күпме белем...

(Л.ШагыйрьҖан)



## **“Яз тамчысы” Республика фестиваленең гала-концерты узды...**

7 апрель көнне “Уникс” концертлар залында “Яз тамчысы” Республика фестиваленең гала-концерты узды. Чарада социаль мәсьәләләр буенча Татарстан Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлеева, эчке сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Президенты Департаменты җитәкчесе урынбасары Роман Беляков, Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима, министрлыклар, ведомстволар, иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашты.

*Дәвамы 2нче биттә ⟶*

***Рубрикалар:***

- ***Бөек шәхес***
- ***Кызыклы вакыйгалар***
- ***Иҗат***
- ***Халык иҗаты***
- ***Хуҗабикә***
- ***Уңган куллар***
- ***Башваткыч***

# “Яз тамчысы”...

Дәвамы

Гала-концертта шулай ук, 61 номинациядә бүләкләнгән 348 студент, 386 артист катнашты.

“Яз тамчысы” инде 21нче тапкыр көллияттә, техникумда белем алучы студентларны бергә җыя.

Фестивальне Республика мәгариф һәм фән министрлыгы, Казанның башкарма комитеты балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты, Татарстан һөнәри белем бирү оешмаларының тәрбия эше буенча Советы, “ТР студентлар лигасы” оештыра.

Барлыгы 8 зона этабы булды: Тәтеш, Чистай, Минзәлә, Бөгелмә, Әлмәт, Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы.

Сайлап алу берничә номинация буенча уздырылды:

- “Белем бирү оешмасының концерт программасы” (30 минутлык тулы программа буларак билгеләнә)
- “Вокал”, “Хореография”, “Театр”, “Үзенчәлекле жанр”, “Арт-профи”, “Фото күргәзмә” (аерым чыгыш ясаучылар билгеләнде)

2017 елны фестивальдә Республика буенча 85 белем бирү оешмаларыннан 13 000 укучы катнашты (4300 артист һәм 8500 тамашачы).

**Безнең Казан педагогия көллияте “Яз тамчы”сында 1 урын алды һәм гран-прига лаек булды.**






Тынгысыз каләм

# Габдулла Тукай

Бөек шәхес

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле,
тик үкенечкә калмасын.



**Тукай – милләтнең милли хисен уятучы халык шагыйредер...**
**Тукай – татар мәдәниятенә онытылмаслык байлыклар бирүче бер татар төзүчеседер...**

*Гаяз Исхакый.*

Әгәр дә дөньяда бик аз яшәп тә, күп эшләр эшләп киткән язучылар турында сүз бара икән, аның берсе, һичшиксез, Габдулла Тукай булыр. Уйлап карасаң, кызганыч тормыш, ятимлек михнәтләрен татыган, яшьли үлеп киткән шагыйрь язмышы бигрәк аяныч.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай 1886 елның 26нчы апрелендә элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте (ТАССР Арча районы) Кушлавыч авылында туа. Кечкенәдән ятим калган Габдулла, кулдан-кулга йөреп, балачагын Сасна, Өчиле, Кырлай авылларында уздыра. Башлангыч белемне Кырлай авылы мәдрәсәсендә ала.

1895 ел башыннан Тукай Уральск шәһәрендә яшәүче туганнары гаиләсендә тәрбияләнә. Биредә ул татар халык иҗатын һәм әдәбиятын җентекләп өйрәнә, гарәп, фарсы, төрек, рус һәм башка халыкларның әдәбиятлары белән таныша, рус теле аркылы Көнбатыш классик әдәбияты казанышларын үзләштерә. Үзе дә беренче шигырьләрен иҗат итә.

Уральскидагы әдәби-мәдәни хәрәкәт Тукай тормышында хәлиткеч роль уйный. 1905 елгы революция дулкыны белән зур әдәбиятка килеп кергән әдип монда җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалаша.

1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. Ул үлемсез әсәрләренең күбесен шушында яза; профессиональ

Тәрәбә

революционерлар даирәсенә керә; татар культурасының революцион-демократик канатын җитәкләүгә алына. Шагыйрьнең сугышчан шигърияте һәм иҗтимагый, әдәби процессларның иң четерекле проблемаларына багышланган публицистик чыгышлары әдәби-мәдәни хәрәкәтнең төп юнәлешен билгеләүче көчкә әверелә.

Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була. Тукай – татар халкының яңа реалистик әдәбиятына һәм хәзерге заман татар әдәби теленә нигез салучы. Шагыйрь иҗтимагый прогресска хезмәт итүне үзенең гражданлык бурычы итеп санады; кыска гына гомер юлында күпкырлы иҗаты белән татар культурасы тарихында яңа эпоха ачты.

Г. Тукайны башка милләт халыклары да үз итте. 1986 елда, шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан, Берләшкән Милләтләр Оешмасының Мәгариф, фән һәм культура буенча комитеты (ЮНЕСКО) бу бәйрәмне халыкара күләмдә билгеләп үтте.

Татар милләтенең сөекле шагыйре, татар әдәбиятында үзенең поэтик мәктәбен тудыру белән бергә, халкыбызның педагогик мәдәниятен үстерүгә дә зур өлеш керткән шәхес.

Габдулла Тукай иҗаты, эшчәнлеге халыкка, туган илгә мәхәббәт идеяләре белән тирәнтен сугарылган. Аның иҗат чоры татар халкының уяну һәм эзләнүләр чорына, татар халкы мәдәниятенең, укыту-мәгариф эшенең яңаруы чорына туры килә. XIX гасыр ахырында татар зыялылары милләтебезнең тормышын, мәдәниятен, уку-укыту эшләрен үзгәртеп кору өчен көрәш башлый, дини-схоластик мәктәпләрдә, мәдрәсәләрдә хөкем сөргән укыту рәвешләрен, ысулларын тамырдан үзгәртүне, укытуны туган телдә алып бару фикерен алга сөрә.

Габдулла Тукай балалар өчен күп әсәрләр язып калдыра: «Энҗе бөртекләре» (1909), «Күңел сәхифәләре» (1910), «Күңел җимешләре» (1911) һ. б. Бу һәм башка әсәрләре татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.

Габдулла Тукай шәкертләр өчен дәреслекләр дә язган. Аның башлангыч сыйныфлар өчен төзелгән «Яңа кыйраәт» («Яңа уку китабы») исемле дәреслеге (1909, 1910) ул чор өчен яңа китап булып саналган. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911) исемле хрестоматиясе дә мәктәпләрдә озак еллар буе укытылган.

Дөньядан китеп барганда Тукайга нибары егерме җиде яшь кенә булган. Шулай яшь булуына карамастан, шагыйрь безнең йөрәккә мәңгегә кереп калган. Бөек Тукай безгә үлмәс әсәрләр калдырган. Ул безне акыллы, тыйнак, гадел булырга өйрәтә, табигатьне, анда булган бар тереклекне яратырга өнди.

Һәр апрель аен - Тукай аен олы хөрмәт белән көтеп алабыз. Синең гомерең нәкъ умырзая чәчәге кебек кыска булды. Әмма иҗат иткән әсәрләрең - мәңгелек!Синең алдыңда баш иябез, бөек Тукай!

*Кәримова Фәридә,212 төркем*

# Яз -…

Кызыклы вакыйгалар



Табигать гел хәрәкәттә, үзгәрештә. Шул үзгәрешләрнең берсе – ел фасыллары алмашыну.

Күзәткәнегез бармы? Ел фасыллары арасында яз - иң матуры, иң ямьлесе.

Озакка сузылган салкын, карлы, буранлы кыштан соң, ниһаять, җиребезгә яз аяк баса. Табигать кышкы йокыдан уянып, җанлана башлый. Кояш үз нурларын көннән-көн күбрәк чәчә. Әйтерсең, бөтен дөньяны тизрәк йокыдан уятырга тели: карларны эретә, гөрләвекләр агыза, тамчылар тамыза, көннәрне озынайта, җылы яктан кошларны чакырып кайтара.

Бу вакытта дөнья үзгәрә, гүя яңадан туа. Агачларда кабат бөреләр бүртә. Күп тә үтми, алар яфрак ярырлар, аннан бар дөнья чәчәккә күмелер: алмагач, шомырт агачлары чәчәк атып, ак күлмәккә төренер.

Язның эше күп: кырларны, бакчаларны кардан арчый, басуларны ача, кешеләрне эшкә өнди. Бакчаларда, урамнарда өмәләр башлана.Кырларда, болыннарда трактор гөрелтесе ишетелә.

Яз тирә– юньгә матурлык, яшеллек алып килә: дымлы җирне үләннәр, аллы-гөлле чәчәкләр белән бизи.

Без барыбыз да язны түземсезлек белән көтеп алабыз.

Яз бит ул - кеше күңеле сафлык белән тулган чак. Яз бит ул - шатлык-сөенечләр килүгә өмет уянган вакыт.

*Гибадуллина Миләүшә,212төркем*



## *Иҗат*

***Иҗат*** **-** гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул. Иҗат ике канатлы ул: яхшыны исбат итү, яманны инкар итү ул, яхшылыкка мәхәббәт, яманлыкка нәфрәт ул!

*Хәсән Туфан*

***

М... шәһәренең бер урамында Әлфинә исемле хатын яшәгән.

Анының бер малае булган. Хатын-кыз Булатны ялгыз үстергән,чөнки ире аларны малай кечкенә булганда ук ташлаган, ә булышырга кешеләре булмаган. Әлфинә, Булат башка малайлардан кимсенмәсен өчен, ике эштә эшләгән. Көндез ул кибеткә сатучы булган, ә кичен хастаханәдә идән юган . Малай әнисенең җылылыгын күрмичә үскән, аны якшәмбе көнендә генә күргән. Бу көн анының өчен иң бәхетле иде . Әтисе белән ул аралашмаган , чөнки ир-атның үз бәхетле гаиләсе булган.

Шулай әнисен күрмичә, Булат унбиш яшькә кадәр үскән. Хәзер инде ул ун яшьлек бала түгел. Әнисе белән бик дорфа сөйләшә башлады, һәрвакыт аны әтисеннән аеруда гаепләгән . Көн саен ул: “ Синең аркада бездән әти китте...”, дип әйтте. Әлфинә бу сүзләрне ишеткәч, улының психикасы турында кайгырды, үзен гаеплегә санады. Ә Булат көннән-көн аннан ераклаша торды. Ананың улы белән тулы итеп сөйләшергә вакыты да булмады. Ул хезмәт хакына Булатка киемнәр алды, ә үзе бер киемнән биш елдан артык йөрде. Әлфинә һаман болай дип әйтә иде: “Минем бар әйберем дә бар. Йокларга өем, ашарга ипием бар. Тагын ни кирәк? Иң мөһиме улым исән-сау һәм тук булсын”. Әни кеше әйберләрне куана-куана алып кайтты, тик малайга алар ошамадылар. Ул аларны әнисе күрмәгән вакытта чүплеккә атты.

*Тәрәбә*

Иҗат

Көннәрнең бер көнендә Булат дуслары белән урамда йөреп кайтырга җыена башлады. Әнисе аңа китәр алдыннан сораулар бирде: “Улым, син дусларың белән кая барасың? Кайчан кайтасың?”. Малай, ишетмәгәнгә сабышып, аларга җавап бирмәде.

Дуслар очрашкач, көнне ничек үткәрергә икәнен фикерләшә башладылар һәм кибеткә барып, берәр әйбер урларга булдылар. Бу алар өчен үзенчәрәк уен иде. Малайлар кызыгып, кибеткә киттеләр. Кергәч, алар, кешеләрнең игътибарын җәлеп итмәс өчен, күп ашамлыклар җыя башлады. Шуннан соң Булат бүтәннәр күрмәгән вакытта кесәсенә шоколад тыгып куйды. (Аның турында ул күптәннән хыялланган иде, чөнки әнисе аңа шоколад алмады. Әлфинә акчаны кирәк әйберләргә генә тотты.) Кызганычка каршы, Булатны әнисенең акчасы бармы-юкмы икәне кызыксындырмады. Малайлар тиз генә чыгабыз дигәндә, аларны бер сатучы апай туктатты һәм кесәләреннән алган әйберләрне чыгартты. Булатның дуслары бөтен алган әйберләрен аның өстенә элеп куйдылар.

Бу вакыйганы әнисе белгәч, аптырашта калды һәм елый башлады. Улы өйгә кайткач, ул аңа: “Нигә син алай эшләдең? Ничек кешенең әйберсен алырга кулың барды? Сиңа нәрсә җитми?” – дип сорады. Булат бер сүзсез чыгып китте. Ул өйгә кайтмыйча, сыйныфташларына китеп барды. Икенче көнне Булат кайтырга булды. Йортына барып җитәргә бер илле метр калып барганда, ул әти-әнисенең бәхәсләшкәнен ишетте. Шул вакытта әтисе: “Әлфинә, бүтән миңа шалтыратасы булма! Мине тынычлыкта калдыр! Минем икенче гаиләм бар. Сез минем өчен беркем түгел. Ә Булат белән булган вакыйгалар миңа кагылмый! Хуш, сау бул!”.

Бу сүзләрне малай ишеткәч, аның башына нидер суккандай булды. Аның башында бер сүз генә иде: “Сез минем өчен беркем түгел…”. Шул вакытта ул әнисе янына йөгерде һәм кочаклап алды: “Әни, мин барысын да ишеттем… Зинһар, гафу ит мине”, - диде.

*Мәрдәнова Айгөл ,212 төркем*

Тәрәбә



*Иҗат*

# ӘКИЯТ

## Әкиятле авыл

Борын-борын заманда яшәгән,ди,бер ярлы,карт кеше. Аның хатыны, ике кызы булган ди. Исемнәре Эвелина һәм Лэвелина.Эвелина әшәке кыз булган, Лэвелина әйбәт, пөхтә кыз була. Алар гел кычкырышып, талашып торганнар.

Кызлар укыганда да Эвелина “4” һәм “5” ле генә, ә Лэвелина “4” һәм “3” леләр ала. Эвелина аннан гел көлә, үзенең “5”леләре белән мактана. Тик Лэвелинаның исе дә китми. Ул үзенең әти-әнисенә яхшы мөнәсәбәттә һәм бик көчле аң-белемле була. Ул гел нәрсәдәндер шикләнә. “Мин, бәлки бу гаиләдән түгелмендер?” – дигән сораулар бирә үзенә.

Болар авылында сихерче Амелия дигән бер хатын яши икән. Ул кешеләрне сихерли, аларга начарлык эшли. Ул, бу гаиләне белеп алгач, Эвелинага түгел, ә Лэвелинага начарлык китерә. Ул аны урлый. Моны кеше белмичә дә кала. Ул аңа нәрсәдер укый, сөйли. Тик Лэвелина аны аңламый. Бу хатын аңа: “Син үләрсең микән, әллә яшәрсеңме? – дип әйтә. Кыз шуннан соң бераз яши әле, ләкин йокыга китә торган була.

Ә беркөнне авырып китә, үләр хәленә җитә. Шуннан Эвелина моңа, сихерче кушуы буенча, даруына кушып йөзек бирә. Лэвелина йөзекне йотып җибәрә. Ул йокыга тала. Аны үлгән дип уйлыйлар. Моның сәбәбе Эвелинада, чөнки ул йөзек биргән дип әйтәләр. Нишләргә дә белмиләр.

Бервакыт Лэвелинаның эче кызара. Аның эчен яралар. Яргач, аның эченнән елан килеп чыга. Аның телендә йөзек була. Елан кешеләргә карап тора да, шул ук минутта Эвелинаны чагып та үтерә. Эвелинаны күмәләр. Ә Лэвелинаны никтер күммиләр. Ул көнгә бер тапкыр күзен ачып ала торган була. Теге еланны эзлиләр, тик ул елан кача.

Елан җир астында яшәүче Аид янына бара. Аид – үлгән кешеләрнең җаннары белән яши икән. Ул Аид янына килә дә: “Үзеңнең базыңны миңа күрсәт әле”, – дип әйтә. Аид моңа күрсәтә. Анда бик күп кеше җаннары була. Елан Аидтан Лэвелинаны кайтаруын сорый. Аид: “Син монда калсаң гына, мин Лэвелинаны теге дөньяга кайтарам”, – ди. Елан каршы килми, шунда ук кеше җаннары янына кереп китә. Өстән Аид карап тора. Елан шул вакытта кеше җаннары арасыннан Лэвелинаның җанын эзләп таба һәм җир өстенә алып чыга. Аид аның батырлыгын күреп, еланны ирекkә җибәрә.

Иртә белән уянып китсә, елан үзенең кешегә әйләнгәнен күрә. Матур егет икән. Егет Лэвелина янына бара да кызга җанын бирә. Кыз терелә. Алар очраша башлыйлар. Алар бергә дус булып, бәхетле яшәп калалар.

*Загрутдинова Люция, 311*



*Тәрҗбә*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*

Шигырьләр

Иҗат



**Тукай – исән!**


Гасырлардан Тукай елмая,
Тик күзләре никтер моңсулар.
Ятимлекнең ачы хәсрәтен
Шигырьләре менә саклыйлар.

Үсмер кыяфәтле ябык шагыйрь
“Җан азыгы” эзләп уйланган:
Гомеренең ахырына кадәр
Каләм тибрәтүдән туймаган!

Гомере кыска, диләр, ләкин:
Тукай – исән!
Тукай – мәңгелек!
Бизгәк тотып яткан чагында да
Каләменә яттыр эшсезлек.

Вакыт – гаҗәп!
Хәтер – иң гаҗәбе.
Тукай үлгән, ләкин үткен теле
Вакыт чикләрен дә җимерде.
Сорау туа йөрәк түләрендә:
Халык хәтерендә мәңге яшәр
Затлар җиргә кабат килерме?!.

*Лилия Нурлы*




Тәрәбә

## Шигырьләр

## Иҗат





Гафу үтенү гөнаһ күк,
Хис итәме кешеләр?
Гафу үтенә белмиләр,
Эшләнсә гаеп эшләр...

Ник авырдыр кешеләргә
Гафу ит, дип әйтергә?!
Бу сорауга җавапны
Беләдер Аллаһ Тагәлә...

*Шакирова Алинә, 921*

Күңел дәфтәремдә моңнар тулса,
Бушанырга алам каләмне.
Әйтеләсе килгән сүзләремнән
Каләм генә аңлый хәлемне.

Һәрбер сүзем чыга йөрәгемнән
Хәтер уйларыма уралып.
Моңнарымның сере каләм белән
Энҗе кебек китә таралып .

Ялгыз калган чакта юлдаш итеп
Каләмемә дәшә серләрем
Сагышларым авырлыгы белән
Сына гына күрмә каләмем .

*Резеда Гараева*

Яз килде!
Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде.
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?
Я, әйтеп кара.

*Г.Тукай*



## Тәрәбә

# Халык сынамышлары

*Халык иҗаты*

Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.

Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.

Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.

Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.

Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.

Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.

Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.

Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.

Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.

Яз көне елгаларда су артмаса,ашлык уңмас.

Яз көне хайван аяк эзләре эресә, җылытыр.

Черкиләр яз көне иртә күренсәләр, һава җылыныр.





*Гәрәбә*

Халык иҗаты

# Зөһрә кыз



Булган, ди, бер карт белән карчык. Аларның Зөһрә исемле бик матур, бик уңган бердәнбер кызлары булган. Бервакыт карчык үлеп киткән. Үлгән вакытында кызына: “Синең үз гомереңдә бер үтенечең үтәлер”, – дип әйткән, ди. Карчыкны җирләгәннәр. Күпмедер вакыт үткәч, карт яңа карчыкка өйләнгән. Бик усал булган ул карчык. Кызга бер дә көн күрсәтмәгән. Кызның әтисе өйдә булса – бер сүз дә әйтми икән, ә чыгып китсә – азаплый башлый икән. Барлык авыр эшләрне кыздан эшләткән бу. Шулай бервакыт, эш булмагач, теге карчык иләк белән су ташырга кушкан кызга. Айлы төн икән. Күк йөзе аяз, ди. Йолдызлар җемелдәшеп торалар, ди. Кыз шулхәтле интеккән су ташып, һич түзәр әмәле калмаган. Айга караган да: “Әй Ходаем, җирдә болай интегеп яшәгәнче, айга ашырыр идең мине”, – дигән. Һәм айга ашкан. Җәбердән котылган. Тулган ай вакытында әтисен сагынуын басалмый гел җиргә карап тора икән ул хәзер.

Тәрәбә

# табышмаклар

**Халык иҗаты**

Ак сыер торып китә,
Кара сыер ятып кала.
*(кыш үтеп, яз килү)*





Аяксыз-кулсыз кое казый.
*(тамчы)*

Ут та түгел, ук та түгел,
Күзгә төшә, карны кисә.
*(кояш нуры)*

Ак юрганымны алып куйдым,
Яшел юрганымны җәеп кудым.
*(яз килү)*



Үзе туңа, өйгә керми,
Үзе җылый да җылый.
*(яз көне түбәгә каткан боз сөңгесе)*

Борынсыз чыпчык боз тишә.
*(тамчы)*

Агач башында йорты,
Эчендә яши җырчы.
*(сыерчык)*





**Тәрәбә**

# Тәмле салат рецепты

Хуҗабикә

- Тавык ите ваклап турала һәм тәлинкә төбенә җәеп салына.
- Пешкән кишер вак кына итеп турап салына.
- Маринадланган гөмбә турап салына.
- Ваклап туралган суган.
- Ваклап туралган йомырка.
- Кукуруз (банкалап сатыла торганы) салына.

- Майонез ягыла, салат кырыйларына чипцы тезелә, тик анын җебүе ихтимал, шуңа күрә аны йомырка сарысы белән алыштыру кулайрак. Аны көнбагыш чәчәгенә охшатып, салат кырыен бизисең.




Телләрне йотарлык!




Тәмле булсын!

Гәрәбә

# Төнбоеклар

*Уңган куллар*



Бу номерның *“Уңган куллар”* рубрикасында без сезгә бик гади һәм матур кул ясалмасын тәкъдим итәбез. Аны өйдә һәм шулай ук бакчага да чыгарып куярга була.

## *Пластик шешәләрдән төнбоеклар*



*Кирәкле материал:*

- Пластик шешәләр (сары һәм ак төс).
- Кайчы.
- Клей.

*Эш тәртибе:*

Сары төсле шешәдән төнбоекның үзәген әзерлибез.

Шул ук шешәдән тасмалар кисәбез (булачак серкәчләр). Тасмалардан спираль формасын ясап, клей белән ябыштырабыз. Соңыннан төнбоек узәгенә серкәчләрне ябыштырабыз. Ак төсле шешәләрдән яфраклар кисеп куябыз(3-4 шт). Шешә башына кигезеп шулай ук ябыштырып куябыз. Төнбоекның төп өлешен әзерләр өчен биш литр шешәне кисеп, бер бит әзерләп куябыз(булачак яфраклар).



*Тәрәбә*

Аларны яшел төскә буйыйбыз. Әзер чәчәкне ярык ясап яфракка ябыштырабыз.

Уңган кулар

1)




2)




3)



4)

Уңган куллар





6)

7)





Уңышлар!

Насибуллина Альбина,212




Тәрәбә

Башваткыч

# Уйлап карыйк әле…














Тәрәбә



# Кроссворд

Башваткыч



**Горизонталь буенча:** 1. Экономикада: базис – "икмәк", ә "тамаша"сы нәрсә? 5. Җир өстендә болыт. 7. Талдан үрелгән койма. 10. Чирдән арындыру. 11. Кыска, йомшак текле ефәк тукыма. 12. Авырлыкка таяныч. 13. Шахматта королынең җиңелүе. 15. Тиз онытучан. 18. Үсемлек өчен туклыклы матдә. 20. Дулкыннарның кушылуы яки кисешүе. 23. 20-30 яшьлардәге таза, гаскәри хезмәткә иң беренче барырга тиешле ир-егет. 26. АКШның төньяктагы штаты. 29. Күрсәтү сүзе. 31. Җитештерергә, сатарга, сатып алырга рөхсәт ителгән товар күләме. 32. Авызның түбәнге, бугазның өске өлеше. 33. Алачыкта эшләүче кеше. 34. Озын аяклы һәм озын томшыклы кечкенә саз кошы. 35. Закон, ныклы кагыйдә. 36. Уку, эш, тамаша арасында ял вакыты.

**Вертикаль буенча:** 1. Идеологик яки сәяси эчтәлекле кыска чакыру. 2. Кыска гына вакыт, әз генә бер ара. 3. Варенье һ.б.ш. ягылган камырны төреп пешерелгән азык. 4. Магний яки алюминийның күкерт тозы: ачы матдә. 5. Өч талак белән аерган хатынны яңадан алу өчен икенче бер иргә никахлату йоласы. 6. Җисемне тәшкил итә торган нәрсә. 8. Кулъязманың бизәклап эшләнгән беренче хәрефе. 9. Чулманга коя торган зур елга. 14. Италия урнашкан ярымутрау. 16. Тавыш бирү юлы белән чыгарылган карар. 17. Ылыслы агач. 18. Формасы үзгәрә торган бер күзәнәкле тереклек иясе. 19. Диңгез, елга, яр буйларының тасвирламасы. 21. Сүс талкыганнан калган салам һәм чүп. 22. Салкын коралдан саклану коралы. 24. Җылы диңгезләрдә дага сыман уграу. 25. Фосфорлы минерал. 27. Каучук ясый торган үсемлек сыгы. 28. Кирпеч сугу өчен балчыкка салам яки тирес кушып ясалган катнашма. 29. Кавказда яшәүче халык. 30. Тирә-як, әйләнә-тирә.



Тәрәбә



Ля-
ля-ля

# Җ□□□□□□ ә□□□




Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделнең камышы;
Таң алдыннан чут-чут килә
Сандугачлар тавышы.

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата;
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата.

Ай былбылым, вай былбылым,
Кунып сайрый талларга;
Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга.



*<u>Әдәби консультант:</u>*
*“ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе җитәкчесе*
*Нуриева Лилия Фаил кызы*
*<u>Баш мөхәррир:</u>Мәрданова Айгөл*
*<u>Редколлегия:</u>*
*“ГӘРӘБӘ” әдәби берләшмәсе әгъзалары*